# Нишләттең син мине... аракы?

Суд залыннан

Таңсылу **Саниева**

**Рюмка арты рюмка күтәреп, җаннарын шешә эчендәге “шайтанга” саткан, аңы томалануы аркасында кеше гомерен кыюга кадәр барып җиткән вәхшиләрнең саны күпме? Бу урында моңа еш кына зыян күрүчеләрнең, ягъни әле кайчан гына бер табын артында утырган шешәдәшләрнең, үзләре тарафыннан да юл куелуын әйтми мөмкин түгел.**



Спиртлы эчемлекләр куллануның азагы кайчан да булса аянычлы тәмамланачагы һәркемгә мәгълүм. Моңа шәһәр суды производствосындагы эшләр ачык мисал. Аларның берничәсенә генә тукталыйк.

34 яшьлек Линаров та (исем-фамилияләр үзгәртелеп бирелә) әнә шул бер авызын тыя алмавы аркасында гомеренең тугыз елын төрмәдә уздырырмын дип уйлады микән? Узган елның башында ул Актүбә бистәсендә урнашкан барларның берсенә кергәч, күптәнге танышы Федотовны очрата. Анысы исә бу вакытта дусты Сидоров белән кәеф-сафа корып утырган була. Билгеле, шешә аларның барысын да “дуслаштыра”. Инде ару гына салып алган ир-атлар бардан чыккач та аерыла алмыйлар. Уйлашалар да, шешәләрен кыстырып, Федотовның күптәнге танышы Хунафинның фатирына барырга булалар. Кайда егыласымны белсәм, салам түшәр идем, диләр бит. Хунафин да бу очрашуның ни рәвешле тәмамланасын белсә, төн уртасында ишеген ачып, әлеге өч исерек ирне фатирына кертмәс иде, мөгаен. Әмма ул чакта барысы да күңелле була: эчәргә бар, дуслар янда. Каннары кызган кеше нишли? Билгеле, болар да кем узардан сүз көрәштерергә тотыналар: мин яхшы да, мин дөрес... Бераздан Хунафин фатирына килгән төнге кунакларга тавышланмаска куша. Шуннан алар барысы да урамга чыгарга булалар. Әнә шул вакытта үзен рәнҗеттеләр дип уйлаган Линаров кесәсендә йөрткән пычагын эшкә җигә... Судта ул кемне күпме кыйнаганын да тәгаен генә белмәвен, ул төнне булган канлы вакыйгаларны өзек-өзек кенә хәтерләвен, аны кыйнарга теләүләрен, качуын, үзенең йорт подъездында гына аңына килүен әйтә. Шуннан ул тиз генә юына да, такси белән Әлмәт шәһәренә чыгып китә. Ә бу вакытта берничә тапкыр пычак кадау нәтиҗәсендә авыр яраланган Хунафин үзенең фатирының ишек төбендә вафат була. Әле кайчан гына бергә кәеф-сафа корып утырган Сидоров белән Федотовка да өлеш чыга.

– Линаров РФ Җинаятьләр кодексының 105 маддәсенең 1 нче, 115 нче маддәсенең 2 нче бүлеге нигезендә гаепле дип табылды. Ул җәза рәвешендә 9 ел да бер айга ирегеннән мәхрүм ителә...

Судьяның авыр чүкече әллә өстәлгә, әллә йөрәкнең үзенә үк төште, монысын Линаров әле бик озак аңламый утыра бирде...

Кеше өчен болай да санаулы гына итеп бирелгән әнә шул кадәр гомерен, ә иң мөһиме, әле рәхәтләнеп яшәп-яшьнәрдәй елларын, каты режимлы колониядә, тимер рәшәткәләр артында уздырачак ул.

Моннан тыш, аңа әле Хунафинның апасына 1 миллион сум күләмендә әхлакый зыянны каплауга компенсация дә түләргә туры киләчәк.

Беренче җинаятен 24 яшьтә кылып, гомеренең яртысын диярлек – 21 елдан артыгын рәшәткә артында уздырган Галиев моннан бернинди дәрес тә алмаган, күрәсең. Чираттагы тапкыр иреккә чыккач, эшкә урнашып йөргәндә ул Хуҗиев белән таныша. Эшкә чакыру көткән арада алар Актүбәгә кайтырга уйлыйлар. Әмма вакытны бушка “үткәрмиләр”: 10 декабрьдән 15енә кадәр эчеп, бәйрәм итеп йөриләр. Шул арада Галиев Алла исемле хатын белән танышырга да өлгерә, аңа барып кунып йөри. Аның ире бу вакытта сырхауханәдә дәвалану узган була. 15 декабрь көнне алар бергәләп Хуҗиевнең фатирына киләләр. Бу вакытта анысы өч кеше белән спиртлы эчемлекләр кулланып утырган була. Бераз вакыттан Хуҗиев һәм Галиев арасында бәхәс туа. Бу урында ызгышны каза күрүче тарафыннан башлануын да әйтеп үтәргә кирәк. Тәмам кызып киткән ир-атлар тынычлана алмыйлар, йодрыклашуга күчәләр. Шул вакытта Галиев өстәлдә яткан пычакны капшап ала һәм шешәдәше күкрәгенә кадап, яшәү өчен мөһим органнарын җәрәхәтли. Яраланган ир-ат идәнгә ава, әмма Галиев туктамый, янә кинәнә. Соңыннан аның Хуҗиевны 13 урыннан яралавы ачыклана. Берни булмагандай фатирдан чыгып киткән гаепләнүчене икенче көнне иртән Алланың фатирында кулга алалар. Судта катнашкан шаһитлар исә ирләрнең башка бүлмәдә булулары, бу вакытта бернәрсә сизмәүләре турында әйтәләр. Моңа аптырыйсы да түгел, чөнки аларның берсе генә дә нәрсәдер ишетер, аңлар, кемгәдер ярдәм итәр хәлдә булмый. Судта да ул көнне чама хисен югалтып, бик күп эчүләрен искә алалар. Экспертлар соңыннан Хуҗиевнең канында этил спиртының күләме кеше үтерерлек дәрәҗәдә булуын ачыклый.

2024 елның 16 февралендә Яр Чаллы суды чыгарган җәза карарын да өстәп, суд Галиевны каты режимдагы төзәтү колониясенә җибәреп, 13 елга ирегеннән мәхрүм итү турында хөкем карары чыгарды.

Менә шулай, исереклек һичшиксез бер-бер якка илтеп чыгара: ул гомерлек күңел ярасы, я булмаса тән ярасы ясый, тагын да аянычрагы – үлемгә яки төрмәгә илтә. Кулга шешә, стакан тотканчы, эчүнең ахыргы нәтиҗәләре хакында ныклап торып уйлансак иде.

# Поручитель булганчы, җиде кат уйла

Кеше һәм хокук

Ирина **Газизова,**
**Азнакай шәһәр суды судьясы**

**Кредит алучы да, аңа поручитель булып баручы да, банк каршында бертигез дәрәҗәдә җаваплы.**

Кредит алу – бүгенге тормышыбызда киң таралган күренеш. Әлеге акчалар ярдәмендә күчемсез милек тә, автотранспорт чаралары, көнкүреш техникасын да, башкасын да алабыз. Моның белән бергәттән кредит һәм займ шартнамәләре (договор) буенча үз йөкләмәләрен үтәмәүче яки тиешенчә үтәмәүче кешеләр саны да арта. Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 807 маддәсе нигезендә, займ шартнамәсе буенча бер як икенче якка милеккә акча яки башка әйберләр бирә, ә заемщик аларны кире кайтарырга йөкләмә ала. Килешү акча яки башка әйберләр хуҗасына тапшырылганнан соң, төзелгән дип санала.

2024 елның 9 аендагы суд практикасы күрсәткәнчә, судта каралган эшләрнең 199 ы – кредитлар буенча бурычларны юллау турында (180 дәгъва юридик затларга, 19ы физик затларга белдерелгән). 169 эш буенча дәгъва таләпләре тулысынча канәгатьләндерелгән, дүртесе буенча – дәгъвачының дәгъвадан баш тартуына бәйле рәвештә производство туктатылган. Бер эш буенча җәмәгать килешүе төзелгән, ике эш башка судка бирелгән.

Кагыйдә буларак, кредит алганда шулай ук җаваплылыкны үз өстенә алучылар да (поручитель) катнаша. Алар банк каршында кредит алучы белән бертигез дәрәҗәдә җаваплы. Әмма заемщиклар һәм поручительләр еш кына бу хакта уйламый. Мисал өчен, берәү кредит алган. Аны түләмәгәч, бурычны юллау өчен, банк биргән дәгъва кысаларында гражданлык эше каралды. Җавап тотучыларның берсе – поручитель. Судта ул үзенең поручитель булып баруын, шул исәптән банк каршында бурычлы булуын таныса да, акчаны алган, аннан файдаланган кеше җавап тотарга тиеш дигән фикерен җиткерде. Эш банк таләпләрен тулысынча канәгатьләндерү белән тәмамланды, ягъни суд бурычны җавап бирүчеләрнең барысыннан да бертигез түләттерде. Мондый күңелсез дә, кызганыч та хәлләргә юлыкмас өчен, бик нык уйлап эш итү сорала. Банкта шартнамәләр төзегәндә физик затларга аларның шартларын җентекләп өйрәнергә һәм үз өстенә алган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, моның азагы нәрсә белән тәмамланырга мөмкин булуын аңлап эшләргә, юридик затларга заемщикларның һәм поручительләрнең түләү сәләтен тикшерергә кирәк.